

# КАЛӘМ ТИБРӘТҮЧЕЛӘР

98 нче татар-рус урта гомуми белем бирү мәктәбе
**№9 МАЙ 2024 ел**

## Рәхмәт сезгә, рәхмәт, ветераннар!

Хыялларда йөрткән Җиңү таңын
Ямьле язлар алып килделәр.
Ватаным, дип, утка керәләр уллар,
Ул вакытта япь-яшь иделәр.
Мең үлемне җиңеп, каһарманнар
Каршы торып дошман явына –
Кичте алар Сиваш сазлыкларын,
Күтәрелде Карпат тавына.
Һәммәбезгә бары тик бер Җиңү,
Тик бер Җиңү кирәк иде шул.
Рейхстагка ал байракны элгән
Татар егете Гали иде ул!
“Онытмагыз безне!” – дияләр күк
Яу кырында ятып калганнар.
Освенцим һәм Дахау мичләрендә
Тере килеш утта янганнар.
Мең яшәгез, илем солдатлары,
Курку белмәс кыз һәм егетләр!
Фашистларны тар-мар итеп, илгә
Җиңү яулап кайткан бөркетләр.
Рәхмәт сезгә, рәхмәт, ветераннар,
Көч бетмәсен солдат җанында.
Насыйп итсен каршыларга бергә
80 нче Җиңү таңын да!

**Алтын-көмеш яуган җирдән туган-үскән ил артык**

*..Палач үзе кача көнбатышка,*
*Өстерәлә ватык көймәсе!*
*Куа аны арттан ядрә булып*
*Ана каны, бала күз яше...*

Бөек Ватан сугышының үткәненә 79 елдан артык вакыт үтте. Мин үзем дә, әти-әнием дә сугыш чорын күрмәдек. Без аны Дәү әниләребездән ишетеп беләбез. Бу канкойгыч сугыш турында ишетеп кенә беләбез. Сугыш дип әйтүгә, минем күз алдыма җимерелгән йортлар, актарылып беткән болыннар, ятим балалар килеп баса. Әйе, рәхимсез сугыш илебез халкына әйтеп бетергесез кайгы-хәсрәт китергән. Яшь-яшь егетләр, кызлар, туган җирләрен саклау өчен, фронтка киткәннәр. Тылда калганнар да солдатлар өчен җылы оекбашлар, бияләйләр бәйләгәннәр. Җиңү өчен дип, бар тырышлыкларын куйганнар. Сугыш бик күп гаиләләргә кайгы, ачы күз яшьләре китергән. Я ире, я уллары, я әтиләре Ватан өчен яу кырларында мәңгегә ятып калган. Ачлыктан тилмереп үлүчеләр дә күп була сугыш елларында. Шулай ук фашист концлагерьларында һәлак булучыларның саны да исәпсез. Бу сугышта бик күп якташларыбыз корбан булган. Ләкин халыкның тырышлыгы бушка китмәгән: күптән көтелгән Җиңү көне килгән. Бу көн халкыбыз күңелендә мәңге онытылмас көн булып уелып калыр. Хәзерге вакытта да 9 нчы Май Җиңү көне буларак билгеләп үтелә. Тик шулай да, күпме еллар узса да, халык хәтерендә Бөек Ватан сугышы иң авыр, иң дәһшәтле сугыш буларак сакланыр, һәм халкыбызның кылган батырлыклары һәрвакыт хөрмәт һәм соклану белән искә алыныр!

**югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**Касыймова Гөлнур Наил кызы**




## Бөек Җиңү

1941 нче елның 21 нче июнендә фашист илбасарлары илебезгә басып керәләр. Халкыбыз, бердәм булып, көрәшкә күтәрелә. Яп-яшь егетләр һәм кызлар туган җирне саклау өчен фронтка китәләр. Аларның күпчелеге дәхшәтле сугыш кырларыннан әйләнеп кайта алмый, туган илнең азатлыгы өчен батырларча һәлак булалар. Халкым күп авырлыкларга түзеп, бихисап батырлыклар кылып, бу сугышта Җиңү яулый. Шуңа күрә, бу бәйрәмдә кешеләр елыйлар да, шатланалар да. Җиңү бәйрәме- бөек бәйрәм. Безгә азатлык һәм тынычлык алып килгән ветераннарыбызны без кадерләргә һәм онытмаска тиешбез!

**Манахов Руслан**
**5Б сыйныф укучысы**




**Байлык терәк түгел, берлек терәк**

***Батырлык турында мәкальләр***

Батырлык яуда беленер.
Батыр бер үләр, куркак көн дә үләр.
Батыр-илнең казыгы.
Батыр егет-ил күрке.
Батыр үзе үлсә дә, даны үлми.
Батыр ут булыр, куркак юк булыр.
Батырга таяк та корал.
Батыр башлап җибәрә, аннан мең кул иярә.
Батыр үз халкын яклый.
Батырлыкта - матурлык.
Батырлыгыңны мәйданда сынат.

Шулай ук май ае безнең игелекле ай буларак та билгеле.
Шул уңайдан сезгә ***ихлас теләкләребезне*** җиткерәбез!

Юлыңда нинди генә кыенлыклар,
борчу-хәсрәт, югалтулар,
күз яшьләре очрамасын-Бер үтенеч сиңа.
Түзем бул! Тешеңне кысып яшь аралаш елмай!
Аягыңа бас! Аллаһыбыз тик яраткан бәндәләрен генә сыный!

Тукран тукылдарга туган,
Сандугач сайрар өчен!
Яшим диеп яшәсәнә-
Салып бар җаның көчен!

Үткән тормышка бәйләнмәгез.
Үпкәләп, ачу саклап яшәмәгез.
Бер кешедән дә көнләшмәгез!

Урлашма... Кешенекенә кызыкма!
Һәрвакытта да үз юлың, үз фикерең,
үз кыйблаң булсын! Күңелеңдә
изгелеккә урын ач!

**Табигатьне саклыйк!**

Туган җир, туган як, туган туфрак! Әти-әни кебек бик тә якын һәм кадерле бу сүзләр! Кеше үзенең туган ягы белән горурланганда, иң элек, аның табигате, уңган-булган кешеләре турында сөйләргә ярата. Аңа багышлап шигырьләр, җырлар иҗат итә. Бу, чыннан да, шулай. Һәр кешегә үзенең туган ягының табигате иң матуры, иң гүзәле булып тоела. Саф һавасы да күңелгә шифа булып ята.

Табигать безгә елга-күлләрне, урманнарны, чишмәләрне, болыннарны бүләк иткән. Шушы байлыкның кадерен белеп яшәсәк иде.

Табигатьне саклый белик, дуслар,

Чүп-чар атмыйк тирә-юнебезгә.

Яшеллеккә күмелгән май ае да

Шатлык өсти безнең күңелебезгә!




***<u>Хөрмәтле " Каләм тибрәтүчеләр" гәҗитен укучылар!</u>***

**Бүгенгесе көндә туган илебезнең батыр һәм курку белмәс ир-егетләре Ватаныбызны саклау өчен яу кырында көрәшәләр. Алар үзләрен кыю һәм җиңүләренә ышанган батырлар итеп күрсәтәләр. 11 сыйныф укучылары аларга иң изге теләкләрен теләп хат яздылар. Хәзер берничәсен сезгә дә тәкъдим итәбез!**

**Исәнме, кадерле солдат!** Минем исемем Арина! Мин 11 нче сыйныфта укыйм. Мин шигырьләр иҗат итәргә яратам. Озак еллар бию түгәрәгенә йөрдем, бик теләп бию белән шөгыльләндем. Шулай ук мин психология белән дә кызыксынам. Бүгенгесе көндә мин Казан шәһәрендә яшим.

Хөрмәтле солдат! Мин синең җаваплылыгыңа һәм уңышларыңа сокланам. Туган илебезне саклар өчен син үзеңнең көчеңне һәм гомереңне дә аямыйча көрәшәсең! Безнең буынны тыныч тормышта яшәтүгә зур өлеш кертүең өчен бик зур рәхмәт сина, кадерле солдат! Сиңа Ватаныбызга исән-сау әйләнеп кайтырга язсын!

**Исәнме, таныш булмаган солдат!** Минем исемем Даша! Миңа 17 яшь. Минем яраткан шөгылем- инглиз телен өйрәнү. Бу телдә мин шигырьләр, хикәяләр укырга яратам. Мин сине белмәсәм дә, синең кыюлыгыңа сокланам. Синең туган илебезне саклап көрәшүең безнең өчен бик мохим. Минем уйлавымча, син көчле һәм батыр. Син киләчәктә каршыңа очраган барлык авырлыкны җиңеп чыгарсың дип уйлыйм. Сиңа тормыш юлында гел әйбәт кешеләр генә очрап торсын! Таныш булмаган солдатым, сәламәтлек, уңышлар, көч-куәт, тынычлык һәм уңышлар юлдаш булсын сиңа!!!

Исәнме, кадерле солдат! Минем исемем Нармин. Мин 11 сыйныфта укыйм, күп укырга, сочинениеләр язарга, төрле телләр өйрәнергә яратам. Шул телләр арасында минем өчен иң якыны- татар теле. Мин 5 нче сыйныфтан бирле татар теленнән үткәрелгән олимпиадаларда : мәктәптә, шәһәрдә, республикада гел җиңүче рәтендә. Зур тырышлык таләп итүен белсәм дә, бу телне өйрәнү миңа рәхәтлек бирә. Киләчәктә дә миңа башка телләрне белү югары уку йортында да һәм алган һөнәрем буенча эшләүдә дә ярдәм итәчәк.

Сиңа туган илебезне саклаган өчен һәм авыр булмаган солдат хезмәте өчен зур рәхмәтемне белдерәм. Мин синең белән горурланам! Синең ир кеше буларак батырлыгыңа һәм характерыңның нык булуына мин бик сокланам!

Сиңа исәнлек-саулык, уңышлар, гаиләңә исән-сау әйләнеп кайтуыңны телим!

**Җәйге ял**

Җәйге каникулда мин авылга кайтам. Анда мине әбием белән бабаем колач җәеп каршы ала. Безнең авыл бик матур урында урнашкан. Тирә-ягында урманнар, кырлар. Кырларда шаулап игеннәр, болыннарда чәчәкләр үсә. Елга буенда челтерәп чишмә ага. Мин әби белән бабайга яшелчәләр үстерергә булышам. Бакчада кыяр, помидор, редиска, суган, кишер һәм башка бик күп яшелчәләр үстерәбез. Ә инде каен һәм җир җиләге өлгергәч, дусларым белән болынга җиләк җыярга барабыз. Шулай ук бергәләп балык тотабыз, су коенабыз, велосипедта йөрибез.
Гомумән, мин үземнең авылымны бик яратам. Аның белән горурланам!

**Гатиятуллин Рамазан**
**6А сыйныф укучысы**


**Җәйге ял**

Җәй җитә. 27 нче майдан безнең каникуллар башлана. Мин апам белән авылга кайтам. Анда әбием белән бабаем яши. Авылда минем дусларым күп. Без бергә велосипедта йөрибез, су коенырга барабыз, көтү көтәбез. Миңа авылда бик ошый.

Мин җәйне бик яратам, чөнки җәен матур. Җәй көне бакчада роза чәчәге, ак чәчәк, лалә чәчәге, ә болыннарда мәтрүшкә, кычыткан, үги ана яфрагы үсә. Үләннәрнең барысы да сәламәтлек өчен бик файдалы.

**Гаязов Эмиль**
**5В сыйныф укучысы**






**Редколлегия:**

**Касыймова Гөлнур Наил кызы**

**Әмирхан Еники,23.**
**Тел: 8 (843) 236-24-12**

**Сездән язмалар көтеп калабыз!**